**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

(8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22,chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

## КАРАРЫ

**2015 елның «30» декабреннән** **№ 8-26**

### «Яңа Чишмә муниципаль район Советының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының бюджеты турында» 2014 елның 16 декабрендәге 38-223 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

Яңа Чишмә муниципаль район Советының «2015 елга, 2016 һәм 2017 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының бюджеты турында» 2014 елның 16 декабрендәге 38-223 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 пунктның 1 пунктчасындагы «445 426,3» санын «444 289,2» санына алмаштырырга;

1.1. 1 пунктның 2 пунктчасындагы «448 100,7» санын «447 044,0» санына алмаштырырга;

1.1. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты дефицитының күләме «2 754,8»;

1.2. Карарның «Яңа Чишмә муниципаль районының 2015 елга бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары» дигән 1 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Карарның «2015 елга Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының фаразлана торган керемнәре күләме» дигән 2 нче кушымтасын әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Карарның «Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының 2015 елга чыгымнарының ведомство структурасы» дигән 7 нче кушымтасын әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

4. Карарның «Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының 2015 елга бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнары төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү» дигән 9 нчы кушымтасын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

5. Әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәрен бүлүне расларга.

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә**
**муниципаль районы Башлыгы** **В. М. Козлов**